**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче Хутор авыл торак пунктларында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

2023 елның 22 ноябре № 5

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә “Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче Хутор авылы торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1 нче группа инвалидлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Хутор авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу, тигезләү, юлларны кардан чистарту);
- авыл җирлеге территориясен җәйге вакытта кисү (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенының сайлау хокукына ия катнашучылары исемлегенә 63 кеше кертелде, тавыш бирүдә җыенның 42 кешесе катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен 42 җыенда катнашучы тавыш биргән;

“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш биргән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче Хутор авыл торак пунктларында гражданнар җыеннарын булды дип, гражданнар җыеннары нәтиҗәләрен **дөрес** дип танырга.

2. “Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче Хутор авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1 нче группа инвалидлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Хутор авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу, тигезләү, юлларны кардан чистарту);
- авыл җирлеге территориясен җәйге вакытта кисү (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү)

соравы (мәсьәләсе) буенча карарны **кабул ителде** дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шумково авылы, Үзәк урамы, 4 нче йорт; Олы Укмас авылы,Үзәк урамы, 42 йорт; Хутор авылы, Яшьләр урамы, 5 йорт, Эшнэк Качкалак авылы, Югары урамы, 5 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шумково авыл җирлеге башлыгы: Л.М. Нәҗмиев